| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.04.2023 Балык Бистәсе штп. № 130пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының тәрбиягә бала алган гаиләләреннән балаларны дәүләт оешмаларына кайтару очракларын анализлау буенча муниципаль эксперт комиссиясе турында» 31.08.2016 №144пи карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 21.12.2021 №414-ФЗ Федераль Законына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссияләр турында якынча нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында” 10.02.2020 №120 карарына ярашлы рәвештә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының тәрбиягә бала алган гаиләләреннән балаларны дәүләт оешмаларына кайтару очракларын анализлау буенча муниципаль эксперт комиссиясе турында» 31.08.2016 №144пи карарына (14.03.2017 №46пи, 22.06.2020 №119пи, 18.02.2021 № 32пи редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1) 1.5 пунктта "Татарстан Республикасы Президенты" сүзләрен "Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе)" сүзләре белән алыштырырга;

1.2) 7.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"7.1 комиссия утырышлары эш планнарына ярашлы рәвештә аена кимендә ике тапкыр үткәрелә.»;

1.3) IV бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« IV. Комиссия составы

4.1 Комиссия составына комиссия рәисе, комиссия рәисе урынбасары (урынбасарлары), комиссиянең җаваплы секретаре һәм комиссия әгъзалары керә.

4.2 Комиссия әгъзалары булып профилактика системасы органнары һәм учреждениеләре җитәкчеләре (аларның урынбасарлары), шулай ук башка

дәүләт (муниципаль) органнары һәм учреждениеләре вәкилләре, иҗтимагый

берләшмәләр, дини конфессияләр вәкилләре, балигъ булмаганнар белән эшләү тәҗрибәсе булган гражданнар, тиешле вәкиллекле органнар депутатлары, башка кызыксынган затлар тора ала.

4.3 21 яшькә җиткән Россия Федерациясе гражданы рәис, рәис урынбасары, җаваплы секретарь һәм комиссия әгъзасы була ала.».

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының тәрбиягә бла алган гаиләләреннән балаларны дәүләт оешмаларына кайтару очракларын анализлау буенча муниципаль эксперт комиссиясенең составын расларга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.К. Вафинага йөкләргә.

Җитәкче Д. А. Сатдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма
комитетының 2023 елның 27
апрелендәге 130 пи номерлы
карары белән расланган

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының тәрбиягә бала алган гаиләләреннән дәүләт оешмаларына балаларны кире кайтару очракларын анализлау буенча муниципаль эксперт комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Вафина Айгөл Камил кызы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, комиссия рәисе; |
| Баһаветдинова Гүзәлия Мансур кызы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге башлыгы, комиссия рәисе урынбасары; |
| Мингәрәева Рузилә Раухан кызы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге баш белгече, комиссия секретаре. |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Садыйков Илсур Мансур улы | «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ начальнигы; |
| Гыймадиева Энже Хәмәтвәли кызы | “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ методисты (педагог-психолог) (килешү буенча); |
| Быльнова Елена Васильевна | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча секторының баш белгече (балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиянең җаваплы сәркатибе); |

| | |
|---|---|
| Исмәгыйлов Рафаэль Дәүләтяр улы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Хидоятова Руфина Сиджат кызы | Балык Бистәсе районы «Балык Бистәсе РҮХ» ДАССОның район педиатры (килешү буенча); |
| Әскарова Резедә Рузил кызы | Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы бүлегенең балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәсе инспекторы (килешү буенча); |
| Богова Светлана Алексеевна | “Казан шәһәренең ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыруга ярдәм итү үзәге" ДБУ директоры (килешү буенча). |